# Мөнәвир Гимазетдинов. Әтием истәлегенә бүләк

Аллаһының рәхмәтләре яусын Хәмәт улы Мөнәвир абый Гимазетдиновка! Бөек Җиңүнең 75 еллыгы алдыннан ул мәчетебезгә яңа матур капка ясатып куйды. Ул бу зур һәм завыклы бүләген әтисе Хәмәт абый истәлегенә багышлады.

Хәмәт абый Бәзәкәдән беренчеләрдән булып 1941 елның 23 июнендә фронтка китә. Сугыш юлларын ул данлы 112-нче Башкорт кавалерия дивизиясе сафларында үтеп Берлинда тәмамлый. “За отвагу” медале һәм 3-нче дәрәҗә Дан ордены кавалеры булып 1945 елның сентябрендә авылга кайта.

Барлык авыл кешеләре, мәчет шурасы исеменнән бик зур рәхмәт Сезгә, Мөнәвир абый! Изге эшләрегез Сезгә, балаларыгызга һәм оныкларыгызга йөз булып кайтсын! Сезгә сәламәтлек, гаилә бәхете һәм озын гомер телибез!

*Бәзәкә мәчете имамы Мехәмәтнур хәзрәт. 7 май, 2020 ел*

